КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 28 апрель г.Казань № 291

«Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә күрсәтелгән юридик зат милкендәге «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркы («Алабуга-2» индустриаль паркы) капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында, алга таба оссия Федерациясе законнары нигезендә «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенең устав капиталын арттырып.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 8 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акцияләрнең (өлешләрнең) 100 проценты Татарстан Республикасыныкы булган юридик затлар милкендә булган капиталь төзелеш объектларына һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез милек объектларын сатып алуга капитал салуларны гамәлгә ашыруга, алга таба мондый юридик затларның устав капиталларын Россия Федерациясе законнары нигезендә арттыру белән күрсәтелгән юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында карар кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында» 2019 ел, 23 апрель, 331 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2021 елда «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте (алга таба - акционерлык җәмгыять) милкендәге 611 790,62 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турындагы тәкъдимен

акцияләрнең (өлешләрнең) 100 проценты Татарстан Республикасыныкы булган «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының акционер җәмгыять милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга («Алабуга-2» индустриаль паркы) һәм 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә кабул итәргә.

2. Субсидия бирү өчен каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүче – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы.

3. Субсидия «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2020 елның 27 ноябрендәге 78-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм «2014 - 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 - 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2017 - 2024 елларга Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын булдыру һәм үстерү» ярдәмче программасының «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона» индустриаль паркы инфраструктурасы объектларын («Алабуга-2» индустриаль паркы) төзү, модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү» чараларын гамәлгә ашыруга бюджет чараларын алучы буларак Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына Россия Федерациясе законнары нигезендә акционерлык җәмгыятьнең устав капиталын тиешле дәрәҗәдә арттыруга юнәлдерелгән акционерлык җәмгыятьнең гамәлләрен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанслар һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин